ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 109-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 109-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 409-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның беренче абзацында «20 000» саннарын «23 000» саннарына алмаштырырга;

2) 2 пунктта «20 000» саннарын «23 000» саннарына алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән «Хезмәт ветераны» исеменә ия гражданнарга түбәндәге социаль ярдәм чаралары билгеләнде: айлык акчалата түләү (2025 елга – 630 сум), элемтә хезмәтләренә һәм торак-коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр, теш протезларын һәм колак протезларын түләүсез ясау.

Күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын бирү өчен мохтаҗлык критерие сыйфатында гражданның кереме күрсәткече кулланыла, ул 20 000 сумнан артмаска тиеш.

Татарстан Республикасы законы проекты белән хезмәт ветеранына социаль ярдәм чараларын билгеләү өчен кулланыла торган уртача айлык керемнең чик күләмен 20.000 сумнан 23.000 сумга кадәр арттыру тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исеме булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла, аларны бирү шартларын билгеләү Татарстан Республикасы компетенциясендә.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителә:

«Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карар;

«Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташламалар бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карар.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Россия Федерациясе бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итә.

Керемнәрнең чик дәрәҗәсе үзгәрүгә бәйле рәвештә, социаль ярдәм чараларына хокук ала торган хезмәт ветераннарының фаразлана торган саны 64 618 кеше тәшкил итәргә мөмкин.

Алдан бәяләү буенча, күрсәтелгән гражданнарга социаль ярдәм чараларын бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларына өстәмә ихтыяҗ 2026 ел шартларында елына 1 560,4 млн сум күләмендә бәяләнә.